**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Яңа Александровка авылы торак пунктындаууздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2019 елның 16 ноябре. № 1
10.00
Яңа Адександровка, мәдәният йорты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авылы җирлеге муниципаль берәмлеге Яңа Александровка авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булганм һәрбер кешедән, 1 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, тыш, үзара салым кертү буенча 2020 елда 200 сум салым алу һәм шул җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итү һәм түбәндәге эшләр өчен:

- Зиратларны төзекләндерү һәм киртәләү өчен.

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 237 граждан кертелгән, җыенда катнашучылар саны 135 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 135 кеше тавыш бирде;

җыенда катнашучы 0 кеше «юк» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше канәгать калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Яңа Александровка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - гамәлгә яраклы дип танырга.

«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авылы җирлеге муниципаль берәмлеге Яңа Александровка авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәрбер кешедән, 1 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, үзара салым кертү буенча 2020 елда 200 сум салым алу һәм шул җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итү һәм түбәндәге эшләр өчен: - Зиратларны төзекләндерү һәм киртәләү өчен дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Яңа Александровка авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында «Интернет» челтәрендә (http://bugulma.tatar.ru, «Яңа Александровка авыл җирлеге» бүлекчәсендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**«Яңа Александровка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Е.Г. Гыйрфанова**